**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422700, Республика Татарстан, Высокогорский район, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**«13» сентябрь 2018 ел** № 89

**Красносельский авыл җирлеге Советының 2017 нче елның 10 нче мартындагы 52 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Красносельский авыл җирлегенең норматив-хокукый актын 2017 нче елның 29 нчы декабрендәге 455-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль закон нигезендә илтеп тапшыру максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Красносельский авыл җирлеге Советының 2017 нче елның 10 нчы мартындагы 52 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Халык тыңлауларына чыгарыла:

1) җирлек уставы проекты, шулай ук әлеге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, җирлек уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, конституция (устав) яисә Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш;

2) җирлек бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;

4) генераль план проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проектлары, территорияне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карарлар, рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару буенча расланган кагыйдәләр булмаганда, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның рөхсәт ителгән бер төрен үзгәртү;

5) «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 нче статьясы нигезендә җирлекне үзгәртеп кору өчен тавыш бирү юлы белән яисә гражданнар җыеннарында белдерелгән җирлек халкының ризалыгын алу таләп ителгән очраклардан тыш, җирлекне үзгәртеп кору турындагы мәсьәләләр.

1.2. 10 нчы булекне түбәндәге эчтәлекле 10.8 пункты белән тулыландырырга:

«10.8. Гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе җирлек халкына гавами тыңлаулар уздыру вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр итүне, муниципаль хокукый акт проекты белән алдан ук таныштыруны, җирлек халкының гавами тыңлауларында катнашуын, гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен бастырып чыгаруны (халыкка җиткерүне) тәэмин итә торган башка чараларны күздә тотарга тиеш.».

2. «Красносельский авыл җирлегенең 2017 нче елның 10 нчы мартындагы 52 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»гы 2018 нче елның 4 нче маендагы 80 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар Интернет челтәренең Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Совет рәисе
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин